| | |
|---|---|
| Совет Старочукалинского<br>сельского поселения Дрож-<br>жановского муниципального<br>района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Чүпрәле муниципаль<br>районы Иске Чокалы<br>авыл җирлеге Советы |

==========================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы авылы

21 август 2023 ел № 29/2

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

**1** Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2)салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3)салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4)гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы

5)« Башкару производствосы турында » 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3, 4 пунктларында билгеләнгән очракларда башкару производствосын тәмамлау һәм җәзага тартылучыга башкарма документларны кайтару турында суд пристав-башкаручының карары чыгару һәм мондый бурычка карата башкарма документларны кабат күрсәтү срогы тәмамлану.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез

дип тануның өстәмә нигезләре турында»2022 елның 15 ноябрендәге 21/2 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылсын.

**2**. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга
**3**. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Низамутдинов